Ноябрь - муниципаль олимпиадалар ае. Татар теле һәм әдәбияты буенча да олимпиада үткәрелде. Уңышлар зур, шуна укучыларым белән горурлана алам.
Татар теле буенча жинүче – дүртәү, әдәбияты буенча - өчәү. Алар: Кузикова Самира, Биксаляева Диана, Чугунова Камила, Кузиков Ильдар, Саликаева Амина. Молодцы! Респуб-лика олимпиадасына хәзерлек бара: класстан тыш индивидуаль биремнәр остендә эш һәм ойгә дә биреп жибәрелгән кызыклы материалларны ойрәнеп килү укучыларга ныклы белем алырга булыша. Әйтеп китим, татар теле һәм әдә-бияты белән берәттән, мәктәбе-бездә башка предметлардан да укытучыларыбыз төрле чаралар үткәрәләр, шул исәптән олимпиадалар да. Горурланырлык нәтижәләр шатландыра: укучыларыбыз ел саен мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендә призлы урыннар яулыйлар.
Шулай ук ноябрь ахырында Татар Пешлә мәктәбе укучылары белән татар теле һәм әдәбияты буенча «Күнелле татар теле» исемле КВН үткәрдек. Олимпиадада жинүчеләр дә катнашты. Үткәрелгән чаранын максаты - татар теле һәм әдәбиятын ойрәнүгә кызыксыну уяту, мәхәббәт хисе тәрбияләү, телне һәм әдәбиятыбызны тагы да тирәнтен ойрәнергә омтылыш тудыру.

КВН туган тел жыры белән башланды, чонки Габдулла Тукаебызнын сүзләренә язылган жыр гимн буларак янгырый. Чараларыбызны шулай еш кына башлап жибәрәбез. Бәйгедә ребуслар, кроссвордлар белән бергә, кызыклы-кызыклы биремнәр бирелде. Ике команда – «Калфаклар» һәм «Түбәтәйләр» командалары ярышты. Конкурслар арасында концерт номерлары булды. Укучылар жырладылар, шигырьләр яттан сәнгатьле иттереп сойләделәр. Ярыш кочле үтте. Ике команда да нык әзерләнеп килгәннәр. Катнашу гына түгел, карап торуы да мавыктыргыч булды. Ахырда - дуслык жинде. Бүләксез жинүче

булмый инде. Командалардагы һәрбер укучы грамоталар һәм татлы призлар белән бүләкләнделәр. КВН кебек чараларда укучылар теләп катнашалар. Димәк, тел беркайчан үлмәс; яшәгән һәм яшәр.
Вакыт тиз үтә. Әйләнеп кararга да олгерә алмаббыз, Яна ел бәйрәме дә житәр. Татар Пешлә гомуми белем бирү урта мәктәбебездә ана әзерлек алып барыла инде. Бездә укыту процессы тәрбия бирү белән бергә үрелеп бирелеп килә.

Сания Саляева